**проект**

**Зеленодольск шәһәре Советы**

**РЕШЕНИЕ**

2019 елның "___"_____________"___________ № __________

«Зеленодольск шәһәре» МБ алган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатларында башкарыла торган чыгымнар юнәлеше турында

«Зеленодольск муниципаль районының финанс - бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтеваның. мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 мартындагы 233 карары, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 26 апрелендәге «Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 379 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

**1.** «Зеленодольск шәһәре» МБ алган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатларында башкарыла торган чыгымнар юнәлеше расларга.

2. «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге тарафыннан һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында алынган башка бюджетара трансфертлар Зеленодольск муниципаль районы бюджетына «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 52 статьясы нигезендә күчерелергә тиеш.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**